РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
Агерзинского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Әгерҗе авыл җирлеге Советы
**БАШЛЫГЫ**

ул. Г. Ахметова, д. 14а, село Агерзе,
Азнакаевского муниципального района, 423303
Тел. (факс) 8(8-5592) 44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

Г. Әхмәтова урамы, 14а, Әгерҗе авылы
Азнакай муниципаль районы, 423303
Тел. (факс) 8(8-5592) 44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» ноябрь 2019 ел № 17

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез торак пунктында гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенч агражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 01 декабрендә 10 сәгать 00 минутта үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә:Советская урамы 1 йорттан 54 йортка кадәр, Центральная урамы 1 йорттан 75 йортка кадәр. Үткәрү урыны: Мәнәвез авылы мәдәният йорты.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 01 декабрендә 14 сәгать 00 минутта үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә:Болотная урамы 2 йорттан 7а йортка кадәр, Чулпан урамы 1 йорттан 14а йортка кадәр. Үткәрү урыны: Чулпан урамы, тегермән каршында.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 07 декаберендә 10 сәгать 00 минутта үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә: Зирекле урамы 1 йорттан 11 йортка кадәр, Полевая урамы 40а йорттан 44 йортка кадәр, М.Җәлил урамы 1 йорттан 10 йортка кадәр, Сосновая урамы 1а йорттан 12 йортка кадәр, Алмалы урамы 1 йорттан 12 йортка кадәр. Үткәрү урыны: М.Җәлил урамы 6 йорт каршында.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 07 декаберендә 14 сәгать 00 минутта үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының дүртенче этабын билгеләргә: Наратлы урамы 1 йорттан 20 йортка кадәр, Г.Тукай урамы 1 йорттан 7 йортка кадәр, Азатлык урамы 3 йорттан 5 йортка кадәр. Үткәрү урыны: Г.Тукай урамы 1А йорты каршында.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Әгерҗе торак пунктында үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Башкарма комитеты.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзарасалым кертү һәм бу акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Мәнәвез авылы, Чулпан урамы буенча юлга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, эшләр өчен килешү буенча түләү);
- мәгълүмати стендлар әзерләү һәм урнаштыру;
- Центральная урамындагы юлга ясалма тигезсезлек урнаштыру;
- Мәнәвез авылында («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халык – ара өлкәннәр көне», "Корбан") бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү;
- трактор йөртүчесенә хезмәте өчен түләү.

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Әгерҗе авылы, Г.Ахметова урамы, 1 йорт адресы буенча, Әгерҗе авылы, С.Хаким урамы, урам чатында, Әгерҗе авылы, Г.Гафиятуллина урамы, 10 йорт белән 23а йорты арасында урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык Н.Н.Хәсәнов